**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урманай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Урманай авылы №28/144 « 28 » ноябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 36/107 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында (19.08.2015 №18/131, 09.08.2017 №09/56, 19.10.2018 №29/113, 11.07.2019 №18/141, 05.11.2019 №26/149, 05.10.2020 №11/11, 15.03.2021 №04/24, 12.08.2021 №18/38, 11.12.2023 №24/110 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Урманай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 36/107 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында (19.08.2015 №18/131, 09.08.2017 №09/56, 19.10.2018 №29/113, 11.07.2019 №18/141, 05.11.2019 №26/149, 05.10.2020 №11/11, 15.03.2021 №04/24, 12.08.2021 №18/38, 11.12.2023 №24/110 карарлар редакциясендә)
түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2 пунктчасында «(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен «, эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән һәм һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: Э.Р.Абдуллина